ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843)211-66-94, E-Mail: gkbioresursy@tatarstan.ru, сайт: http://ojm.tatarstan.ru

Приказ Казан шәһәре Боерык

15.01.2026 № 7- од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 16.05.2018 № 126-од боерыгы белән расланган Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән,

**боерам:**

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының (алга таба – Комитет) «Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 16.05.2018 № 126-од боерыгы белән расланган Федераль әһәмияттәге

аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, (Комитетның 2018 елның 14 ноябрендәге 344-од номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 389-од номерлы, 2020 елның 12 августындагы 232-од номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 350-од номерлы, 2021 елның 12 августындагы 235-од номерлы, 2021 елның 23 сентябрендәге 287-од номерлы, 2022 елның 02 декабрендәге 405-од номерлы, 2023 елның 03 августындагы 225-од номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 342-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән), аны яңа редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә (кушымта итеп бирелә).

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәтләре күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга регламентларның нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 16 маендагы 126-од номерлы боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2026 елның 15 гыйнварындагы 7-од номерлы боерыгы редакциясендә)

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын кулланугa рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт үхезмәте) административ регламентының стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр: юридик затлар, шәхси эшкуарлар һәм гражданнар (алга таба – гариза бирүчеләр)

Гариза бирүчеләрнең мәнфәгатьләрен гариза бирүче тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар (алга таба – гариза бирүченең вәкиле) тәкъдим итәргә мөмкин.

1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә, алар турында белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба –Бердәм портал), шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Комитет).

Дәүләт хезмәте Комитетның Хайваннар дөньясы мониторингы бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан күрсәтелә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт (алга таба – Рөхсәт) (әлеге Регламентка 5 нче кушымта).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар (әлеге Регламентка 6 нчы кушымта).

2.3.3. Рөхсәтне гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә (әлеге Регламентка 7 нче кушымта);

2.3.4. Рөхсәтне куллану турында хисап кабул итү хакында хәбәрнамә (әлеге Регламентка 8 нче кушымта).

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә Комитетның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә имзаланган электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы (http://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы) яисә Бердәм порталдагы шәхси кабинетына җибәрелә.

Гариза бирүченең сайлавы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе шулай ук комитетта яисә Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) (Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү булганда) кәгазьдә бастырылган, Комитетның тиешенчә вәкаләтле вазыйфаи заты яисә КФҮ хезмәткәренең мөһере һәм имзасы белән таныкланган электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирелә.

Реестр язмасын булдыру зарурлыгы юк.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән, электрон почта аша яки почта аша бирелгән очракта, Рөхсәт яки кире кагу турында карар кабул итү вакыты гариза теркәлгән көннән соң 5 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Рөхсәт яки кире кагу турында карар кабул итү вакыты гариза теркәлгән көннән соң 5 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар КФҮгә бирелгән очракта, Рөхсәт яки кире кагу турында карар кабул итү вакыты заявка теркәлгән көннән соң 5 эш көне тәшкил итә.

Гариза бирүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, Рөхсәт яисә баш тарту турында карар бирүнең максималь срогы 5 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән, электрон почта аша яки почта аша бирелгән очракта, Рөхсәтне

гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә бирү вакыты гариза теркәлгән көннән соң 1 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Рөхсәтне гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә бирү вакыты гариза теркәлгән көннән соң 1 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар КФҮгә бирелгән очракта, Рөхсәтне гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә бирү вакыты гариза теркәлгән көннән соң 1 эш көне тәшкил итә.

Рөхсәтне гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә бирүнең максималь вакыты, гариза бирүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, 1 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән, электрон почта аша яки почта аша бирелгән очракта, РРөхсәттән файдалану турында хисап кабул итү турында хәбәрнамә бирү вакыты хисап теркәлгән көннән соң 1 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, республика Порталында шәхси кабинет аша бирелгән очракта, Рөхсәттән файдалану турында хисап кабул итү хакында хәбәрнамә бирү вакыты хисап теркәлгән көннән соң 1 эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар КФҮгә бирелгән очракта, Рөхсәттән файдалану турында хисап кабул итү хакында хәбәрнамә бирү вакыты хисап теркәлгән көннән соң 1 эш көне тәшкил итә.

Рөхсәттән файдалану турында хисап кабул итү турында хәбәрнамә бирүнең максималь вакыты, гариза бирүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып, 1 эш көне тәшкил итә.

Гариза бирүче КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм беркетелә торган документларны Комитетка Комитет белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда тапшыру тәэмин ителә. Хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануга рөхсәт бирү яки рөхсәт бирүдән баш тарту процедурасын гамәлгә ашыру вакытына гаризаның КФҮдә булу вакыты һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен Комитеттан КФҮгә тапшыру вакыты кертелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны бирү гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска, Республика порталында, Бердәм порталда шәхси кабинетка) җибәрү дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Хайваннар дөньясы объектларыннан аларны аулау юлы белән файдалану өчен рөхсәт биргән өчен 650 сум күләмендә дәүләт пошлинасы алына.

Дәүләт пошлинасы түләү түбәндәге реквизитлар буенча башкарыла:

Түләү алучының атамасы: Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты)

Түләү алучының реквизитлары:

Отделение - ОКЦ № 6 ВВГУ Банка России //Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе Казан шәһәре;

ИНН: 1660111252;

КПП: 165501001;

р/счет: 03221643920000001100;

к/счет: 40102810445370000079;

БИК: 019205400;

КБК: 04810807240011000110.

2.6. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы сорату биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

Гариза бирүчене кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Аерым категорияләр өчен чират тәртибе билгеләнмәгән.

2.7. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү вакыты

Гариза бирүче шәхсән Комитетка, почта аша, электрон почта аша мөрәҗәгать иткәндә теркәлү гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла. Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

Гариза бирүче соратуны Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче сорату биргән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетына һәм электрон почта аша соратуның теркәлү номеры һәм сорату бирү датасы күрсәтелгән, сорату җибәрелүен раслый торган хәбәрнамә ала.

МФЦ аша сорату кергәндә, соратуны теркәү сорату һәм документлар кергән көнне башкарыла.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр Комитетның рәсми сайтында, Бердәм порталда урнаштырылган.

2.9. Дәүләт хезмәтенең үтемлелеге һәм сыйфаты күрсәткечләре.

Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдаланырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре Комитетның рәсми сайтында һәм Бердәм порталда урнаштырылган.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү хакында.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәткәндә, гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 16 статьясындагы 1 өлешенең $7^2$ пункты нигезендә электрон образлары элек таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаларны башкару барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) карата Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган мәгълүмат системасы аша, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру башка формада өстәмә сорату бирү соратуның электрон формасын Бердәм порталда яисә Республика порталында тутыру юлы белән башкарыла (башка формада өстәмә сорату бирү таләп ителми).

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр» гамәли платформасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

Татарстан Республикасы Дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат мәгълүмати стендларда һәм Комитетның рәсми сайтында урнаштырыла.

Дәүләт хезмәте КФҮ аша (Комитет һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү булганда), үзара хезмәттәшлек турында мондый килешү үз көченә кергән вакыттан алып күрсәтелә.

КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, КФҮнең гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге бар.

КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәткәндә, консультация бирүне, документлар кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара.

Гариза бирүче КФҮ аша мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм документларны гаризаны теркәү көненнән алып бер эш көне эчендә Комитетка тапшыру тәэмин ителә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Комитет белән КФҮнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе Комитет белән КФҮ арасында төзелә торган килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек тәртибе – КФҮнең эш регламенты белән җайга салына.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

Гариза бирүче үзе тапшыра торган документларга һәм мәгълүматка һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш булган

гариза бирүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документларга бүленеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен закон һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге әлеге Регламентның 3 нче кушымтасында урнаштырылган.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1. Билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле хезмәтләр һәм документлар бирү турында сорату бирү;

2. 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр: Аулау юлы белән хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

1. Документларның формасы һәм эчтәлеге буенча Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

2. Заявкада (гаризада) һәм аңа кушып бирелгән документларда дөрес булмаган мәгълүматлар булу;

3. Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар дөньясы объектларын куллануга чикләүләр һәм тыюлар кертү;

4. Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында Дәүләт мәгълүмат системасында дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр булмау;

5. Заявкада (гаризада) күрсәтелгән белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынган белешмәләргә каршы килә;

6. Хайваннар дөньясыннан файдалану төре һәм ысулы Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән аулау төрләренә һәм ысулларына туры килми.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, Комитет гариза бирүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп хәбәр итә.

2.12.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәтен

күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, гариза бирүченең категорияләрен (билгеләрен) исәпкә алып, әлеге Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү вакытлары

3.1. Гариза бирүче һәм (яисә) гариза бирүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук гариза бирүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен (дәүләт хезмәтен күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында Карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш), бәяләү үткәрелә торган административ процедураны, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң гариза бирүчегә карата чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны) бүлүне күздә тоткан административ процедураны, гариза бирүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк мәртәбә кабатлау рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын гамәлгә ашыру каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлгә ашырыла торган административ процедуралар исемлеге:

1) гариза бирүченең профилен билгеләү;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

5) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

3.3. Дәүләт хезмәте алдан (проактив) режимда күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны карау статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысуллары

Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны карау статусын үзгәртү турында мәгълүмат бирү автомат режимда Бердәм порталда, Республика порталында гариза бирүченең шәхси кабинетында, шулай ук гариза бирүчеләргә консультацияләр бирү барышында, шул исәптән шәхсән кабул иткәндә Комитетта һәм КФҮдә дә гамәлгә ашырыла.

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

1. Гариза бирүчеләр – юридик затлар, шәхси эшкуарлар һәм гражданнар;

2. Гариза бирүче вәкиле – гариза бирүче тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә аның мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләт бирелгән зат.

3. Республика порталы – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru);

4. Бердәм портал – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/);

5. Дәүләт хезмәте – Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентының стандартын һәм тәртибен билгели;

6. Комитет – Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты;

7. Бүлек – Комитетның Хайваннар дөньясы мониторингы бүлеге;

8. КФҮ – «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;

9. Рөхсәт – Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт

10. 63-ФЗ номерлы Федераль закон – «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон;

11. 210-ФЗ номерлы Федераль закон – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон.

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе исеме | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1 | Рөхсәт | Физик зат | 1А |
| 2 | | Юридик зат | 2А |
| 3 | | Шәхси эшкуар | 3А |
| 4 | | Гариза бирүче вәкиле | 4А |
| 1 | Рөхсәтне гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә | Физик зат | 1Б |
| 2 | | Юридик зат | 2Б |
| 3 | | Шәхси эшкуар | 3Б |
| 4 | | Гариза бирүче вәкиле | 4Б |
| 1 | Рөхсәттән файдалану хакында хисап кабул итү турында хәбәрнамә | Физик зат | 1В |
| 2 | | Юридик зат | 2В |
| 3 | | Шәхси эшкуар | 3В |
| 4 | | Гариза бирүче вәкиле | 4В |

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| № | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның исемлеге | Документлар тапшыруга таләпләр | Документлар тапшыру ысуллары |
|---|---|---|---|---|
| *Гариза бирүче дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен үзе тапшырырга тиешле документлар* | | | | |
| 1 | 1А, 2А, 3А, 4А | Куллануга заявка | Заявканың формасы 7 нче кушымтада бирелгән | Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; Бердәм портал, Республика порталы аша; КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә |
| 2 | 1Б, 2Б, 3Б, 4Б | Рөхсәтне гамәлдән чыгару турында гариза | Гаризаның формасы 10 нчы кушымтада бирелгән | Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; Бердәм портал, Республика порталы аша; КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә |
| 3 | 1В, 2В, 3В, 4В | Рөхсәттән файдалану турында хисап | Хисапның формасы 11 нче кушымтада бирелгән | Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; Бердәм портал, Республика |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | порталы аша; КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә |
| 4 | 2А, 4А<br>2Б, 4Б,<br>2В, 4В | Гамәлгә кую документларының күчермәләре | Устав күчермәсе | Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; Бердәм портал, Республика порталы аша; КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә |
| 5 | 1А, 3А, 4А,<br>1Б, 3Б, 4Б,<br>1В, 3В, 4В | Шәхесне таныклый торган документ | Россия Федерациясе гражданы паспорты яисә Россия Федерациясе законнары нигезендә шәхесне таныклый торган башка документ | Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә |
| 6 | 4А, 4Б, 4В | Ышанычнамә | Законнар нигезендә рәсмиләштерелгән | Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; Бердәм портал, Республика порталы аша; КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә |
| *Гариза бирүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документлар, алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш* | | | | |
| 1 | 1А, 2А, 3А, 4А | Хайваннар дөньясы объектларын ярым ирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә асрауга һәм үрчетүгә рөхсәт күчермәсе | Ярым ирекле шартларда һәм ясалма рәвештә булдырылган яшәү тирәлегендә хайваннар дөньясы объектларын тоту һәм үрчетү | Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; Бердәм портал, Республика порталы аша; КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | өчен – хайваннар дөньясы объектларын асрау һәм үрчетү максатларында аларны аулау юлы белән кулланганда – рөхсәт күчермәсе (Россия Федерациясе субъектларының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану өлкәсендәге вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле органнары) | |
| 2 | 1А, 2А, 3А, 4А | Рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы түләүне раслау | Рөхсәт биргән өчен дәүләт пошлинасы түләүне раслый торган документ (Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе); | Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; Бердәм портал, Республика порталы аша; КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә |
| 3 | 2А, 4А<br>2Б, 4Б,<br>2В, 4В | Юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | Тиешле дәүләт реестрындагы документның күчермәсе (Федераль салым хезмәте) | Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; Бердәм портал, Республика порталы аша; КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | 3А, 4А<br>3Б, 4Б,<br>3В, 4В | Шәхси эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә | Тиешле дәүләт реестрындагы документның күчермәсе (Федераль салым хезмәте) | Комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; Бердәм портал, Республика порталы аша; КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә |

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № | Баш тарту өчен нигезләр исемлеге | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|
| *Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге* | | |
| 1 | Билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле хезмәтләр һәм документлар бирү турында сорату бирү | 1А, 2А, 3А, 4А<br>1Б, 2Б, 3Б, 4Б<br>1В, 2В, 3В, 4В |
| 2 | 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү | 1А, 2А, 3А, 4А<br>1Б, 2Б, 3Б, 4Б<br>1В, 2В, 3В, 4В |
| *Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләрнең тулы исемлеге* | | |
| 1 | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр билгеләнмәгән | 1А, 2А, 3А, 4А<br>1Б, 2Б, 3Б, 4Б<br>1В, 2В, 3В, 4В |
| *Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге* | | |
| 1 | Документларның формасы һәм эчтәлеге буенча Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 2 | Заявкада (гаризада) һәм аңа кушып бирелгән документларда дөрес булмаган мәгълүматлар булу | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 3 | Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар дөньясы объектларын куллануга | 1А, 2А, 3А, 4А |

| | | |
|---|---|---|
| | чикләүләр һәм тыюлар кертү | |
| 4 | Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында Дәүләт мәгълүмат системасында дәүләт пошлинасын түләү турында белешмәләр булмау | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 5 | Заявкада (гаризада) күрсәтелгән белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алынган белешмәләргә каршы килә | 1А, 2А, 3А, 4А |
| 6 | Хайваннар дөньясыннан файдалану төре һәм ысулы Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән аулау төрләренә һәм ысулларына туры килми | 1А, 2А, 3А, 4А |

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты
420021, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кәрим Тинчурин урамы, 29 йорт

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга _____ номерлы рөхсәт

Бирелде:

_______________________________________________________________________

(оешманың, шәхси эшкуарның исеме, физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

Куллану рөхсәт ителә: _________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

Түбәндәге төрләрдәге хайваннар дөньясы объектларын куллану өчен:

| Хайваннар дөньясы объектлары исемлеге (русча һәм латинча исеме) | Саны | Файдаланырга планлаштырыла торган хайваннар дөньясы объектларының җенесе, яше |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Хайваннар дөньясы объектларын куллану урыны: ______________________________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану вакыты: ______________________________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану максаты: _____________________________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану алымнары: ____________________________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану кораллары: ___________________________

Рөхсәтне башка затларга биреп тору тыела.

Гамәлдә булу вакыты тәмамлангач, Рөхсәт аны куллану турында хисап белән бергә ун көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

Бирү датасы: _________________

Рәис _______________________________

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Кемгә: ____________________________

(физик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), (почта һәм (яки) электрон) адресы; юридик затлар өчен: оешманың исеме, (почта һәм (яки) электрон) адресы)

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар

«Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү» хезмәте күрсәтү буенча ________ елның ___ ________________ _____ номерлы гаризаны карау нәтиҗәләре буенча ______________________________ нигезендә _____________________________ сәбәпле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителде.

Әлеге хокук бозуларны бетергәннән соң, Сез кабат Комитетка хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тартуга карата шикаятьне Комитетка җибәрү юлы белән судка кадәр тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

Дата _________________ ______________________________________ ________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (имза)

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Кемгә: ___________________________
(физик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), (почта һәм (яки) электрон) адресы; юридик затлар өчен: оешманың исеме, (почта һәм (яки) электрон) адресы)

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәтне гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә

_______ елның ___ _________________ кергән ____ номерлы гариза нигезендә Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга ___________________ бирелгән рөхсәтне гамәлдән чыгару хакында _______ елның ___ _________________ ____ номерлы карар кабул ителде.

Дата ________________ ____________________________________ ________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (имза)

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Кемгә: ___________________________

(физик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), (почта һәм (яки) электрон) адресы; юридик затлар өчен: оешманың исеме, (почта һәм (яки) электрон) адресы)

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәтне куллану турында хисап кабул итү хакында хәбәрнамә

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәтне куллану турында _____ елның ______________ ________ номерлы хисапны кабул итү раслана №_____________ дата _________________.

Дата _________________ _______________________________________ _________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (имза)

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 9 нчы кушымта

Форма

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга заявка

Гариза бирүче турында белешмәләр: ____________________________________________

(юридик затлар өчен – оешманың тулы исеме,

_______________________________________________________________________

банк реквизитлары, адресы, элемтә өчен телефоны;

_______________________________________________________________________

физик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен – фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта),

_______________________________________________________________________

паспорт мәгълүматлары, адресы, элемтә өчен телефоны)

Хайваннар дөньясы объектларын куллану максаты: ___________________________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану вакыты: ____________________________

Файдаланырга планлаштырыла торган хайваннар дөньясы объектлары исемлеге: ____

Файдалану өчен хайваннар дөньясы объектлары саны (төрләре буенча):

_______________________________________________________________________

Хайваннар дөньясы объектларының җенси һәм яше буенча составы (билгеләү мөмкинлеге булган очракта): _______________________________________________

Хайваннар дөньясы объектларын файдалану территориясе (акваториясе): __________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану алымнары: _____________________________

Хайваннар дөньясы объектларын куллану кораллары: ____________________________

Файдаланыла торган хайваннар дөньясы объектларын тоту шартлары турында белешмәләр:_____________________________________________________________

Рөхсәттән файдалануга җаваплы зат: ______________________________________

_______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

Хайваннар дөньясы объектларыннан файдалануда катнашучы затлар исемлеге:

_______________________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте Идарәсеннән _________ елның ___ _____ ____ номерлы белешмәләр буенча Россия Федерациясе бюджет
(дата)
системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч юк (бар)
(кирәклесенең астына сызарга)

Дата: «___» _________ 20__

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 10 нчы кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә

_________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

кемнән: ___________________________________

(физик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), (почта һәм (яисә) электрон) адресы)
юридик затлар өчен: оешманың исеме, (почта һәм (яки) электрон) адресы)

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәтне гамәлдән чыгару турында гариза

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга миңа бирелгән _________ елның ___ _____ ____ номерлы рөхсәтне _____________ сәбәпле гамәлдән чыгаруыгызны сорыйм.

________________ ______________________ (___________________________________________)

(дата) (имза) (имзаның расшифровкасы)

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 11 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитеты рәисенә

___________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

кемнән: ___________________________________
(физик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), (почта һәм (яки) электрон) адресы; юридик затлар өчен: оешманың исеме, (почта һәм (яки) электрон) адресы)

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәтне куллану турында хисап

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт гамәлдә булган чорда түбәндәге төрләр тотылды, саны: ___________________________________

Дата _________________ ___________________________________ ________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) имза

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 12 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Кемгә: ______________________________
(физик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), (почта һәм (яки) электрон) адресы; юридик затлар өчен: оешманың исеме, (почта һәм (яки) электрон) адресы)

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү өчен документлар кабул итүдән баш тарту турында карар

«Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү» хезмәте күрсәтү буенча ________ елның ___ ________________ ____ номерлы гаризаны карау нәтиҗәләре буенча _____________________________ нигезендә ____________________________ сәбәпле хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителде.

Әлеге хокук бозуларны бетергәннән соң, Сез кабат Комитетка хезмәт күрсәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Әлеге баш тартуга карата, шикаятьне Комитетка җибәрү юлы белән судка кадәр тәртиптә, шулай ук суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

Дата _________________ ___________________________________ ________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) (имза)

Федераль әһәмияттәге аеруча саклаулы табигый территорияләрдәге, шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш, хайваннар дөньясы объектларын куллануга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 13 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә

_______________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)

_______________________________

(физик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен: фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), (почта һәм (яки) электрон) адресы; юридик затлар өчен: оешманың исеме, (почта һәм (яки) электрон) адресы)

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны рәсмиләштергәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм

_______________________________________________________________

(бирелгән документ)

күрсәтелгән

_______________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:

_______________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1. _______________________________________________________________

2. ______________________________________________________________________

Документның әзерлеге турында миңа ______________________________ хәбәр

(хәбәр итү ысулы)

итүегезне сорыйм.

________________ ________________(____________________________________________)

(дата) (имза) (имзаның расшифровкасы)